КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1180

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2020 ел, 17 март, 192 нче; 2020 ел, 14 июль, 590 нчы; 2020 ел, 5 август, 656 нчы; 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче; 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12*);

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгариф оешмалары типлары һәм белем бирү дәрәҗәләре яктылыгында мәгариф белән идарә итү (04.05.01*);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашу урыны буенча теркәлгән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга (яшәү урыны буенча теркәлгән индивидуаль эшмәкәрләргә) («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш) карата мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт контроле (күзәтчелеге) (04.05.02*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

ваклап сату базарларын оештыруга, ваклап сату базарларында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (03.05.03*);

социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән Россия Федерациясе субъектларындагы башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү (03.07*).

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

архитектура эшчәнлеге белән идарә итү (01.04*);

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү (01.05.03*);

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән идарә итү (04.01*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән идарә итү (01.13*);

альтернатив граждан хезмәтен оештыруны тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан хәрби бурычның үтәлешен тәэмин итү (02.02*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән цифрлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты белән Татарстан Республикасы территориясендә мәдәни мирас объектларын саклау (саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру) өлкәсендә иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.28*).»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.4[1] пунктча өстәргә:

«3.3.4[1]. Иҗади (креатив) индустрияләрне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшли һәм иҗади (креатив) индустрияләрне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын тормышка ашыра;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин